**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 апрель № 303

г. Казань

Юридик затларга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм бүтән чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм юридик затларга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм бүтән чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтару максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлә торган Юридик затларга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм бүтән чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлүен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\303.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 апрель, 303 нче
карары белән расланган

Юридик затларга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм бүтән чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип юридик затларга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы тармагында күргәзмәләрдә һәм бүтән чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтару максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен (алга таба – чаралар, субсидияләр) билгели.

2. Субсидияләр юридик затларга Татарстан Республикасы территориясендә житештерелә торган авыл хужалыгы продукциясен сату базарларын тәкъдим итү һәм киңәйтү максатларында Татарстан Республикасының чараларда катнашуы белән бәйле чыгымнарын кайтаруга бирелә.

3. Субсидияләр күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Авыл хужалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованияләре һәм бюджет ассигнованияләре лимитлары кысаларында биреләләр.

4. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен тормышка ашыручы һәм түбәндәге шартларга җавап бирүче юридик затларга аларның оештыру-хокукый рәвешенә карамастан (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән гайре) биреләләр:

Россия Федерациясе бюджет системасында бюджетларга мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары булмаган;

чаралар оештырган һәм үткәргән.

5. Субсидияләр алу өчен юридик затлар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гаризаны;

Министрлык раслаган форма буенча чаралар үткәрүгә чыгымнар сметасын;

чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар булуын раслый торган документларны;

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга булган барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләрен;

Министрлык раслаган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында белешмә-хисапны.

6. Юридик затлар үз ихтыярлары белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне;

Россия Федерациясе бюджет системасында бюджетларга мәҗбүри түләүләр буенча кредит бурычлары булмауны раслый торган документны.

7. Юридик зат әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Министрлык күрсәтелгән документларны ведомствоара багланышлар тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык:

а) субсидияләр бирү турында гаризаларны алар кергән көндә журналга терки, ул номер сугылган, шнурланган һәм мөһер белән таныкланган булырга тиеш;

б) гаризалар теркәлгән көннән соң 20 көн эчендә тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 5 пунктына туры килгәнлекне карап тикшерә;

в) тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 5 пунктына туры килгәнлеге билгеле булганда әлеге пунктның «б» ярдәмче пунктында билгеләнгән вакыт үткәннән соң бер эш көне эчендә юридик затка субсидия бирү турында карар кабул итә;

г) тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 5 пунктына туры килмәгәнлеге билгеле булганда әлеге пунктның «б» ярдәмче пунктында билгеләнгән вакыт үткәннән соң юридик затка тиешле документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Юридик зат хәбәр алган көннән соң өч эш көне эчендә эшләнеп беткән яки җитмәгән документларны Министрлыкка тапшырырга хокуклы.

Эшләнеп беткән яки җитмәгән документлар билгеләнгән вакытта тапшырылган очракта мондый документлар тапшырылган көннән соң бер эш көне эчендә Министрлык субсидия бирү турында карар кабул итә. Эшләнеп беткән яки җитмәгән документлар билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта әлеге ярдәмче пунктның икенче абзацында билгеләнгән вакыт үткәннән соң бер эш көне эчендә Министрлык субсидия бирергә рөхсәт итмәү турында карар кабул итә.

д) тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында юридик затка язма рәвештә хәбәр юллый.

9. Субсидия бирү Министрлык һәм субсидия бирү турында карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң ике эш көне эчендә субсидия бирү турында килешү төзелә.

Субсидия бирү турында килешү формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Субсидия бирү турында килешүдә субсидия зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, агросәнәгать комплексы тармагында чаралар үткәрү белән бәйле чыгымнар төре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияне файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыкларын субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартлары, максатлары һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы, субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешүне үтәве турында нигезләмәләр күздә тотыла.

10. Министрлык бюджет чараларын баш бүлүче булып тора һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган үзенең исәп-хисап счетыннан тиешле субсидияләр турында белешмә-хисаплар нигезендә юридик затларның исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы «б» ярдәмче пунктында күрсәтелгән вакыт үткәннән соң биш көн эчендә субсидияләр күчерүне гамәлгә ашыра.

11. Әлеге Тәртип белән билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан билгеләнештә файдаланмау һәм (яки) субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактлары билгеле булганда Министрлыкның тиешле таләбен алган датадан соң 60 көн эчендә субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

12. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр, субсидияләр калдыклары хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемә кире кайтарылырга тиеш.

13. Әлеге Тәртипнең 11 нче һәм 12 нче пунктларында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә тартып алынырга тиеш.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максаты һәм тәртибе үтәлүне законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүне гамәлгә ашыралар.

15. Бюджет чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.

---

F:\KARAR\2015\303-1.docx